| | |
|---|---|
| СОВЕТ СМАИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СМӘЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«19» гыйнвар 2026 ел. № 21

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең чикләрен туры китерү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач район Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләре турында» 2025 елның 17 декабрендәге 28 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең чикләрен туры китерү буенча 2026 елның 14 январенда уздырылган гавами тыңлаулар нәтиҗәсе буенча халык фикерен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең чикләрен тәңгәлләштерүне Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чикләренә туры китерү белән килешергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (https://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Смәел авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Йосыпов